ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2024 г.Казань № 570-87/тэ-2024

2025-2027 елларга Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте кулланучысына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 17.12.2024 ел, №34-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Түбән Кама муниципаль районының «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан «Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте кулланучысына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2024 № 570-87/тэ-2024
карарына кушымта

«Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан
«Энергошинсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте кулланучысына җиткерелә
торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2025-2027 елларга
календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | "Түбән Кама ҖЭҮ" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 881,59 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 998,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 998,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 028,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 1 028,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 1 069,23 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге